**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Тюгеевского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

ул. Центральная, д. 8, с. Тюгеевка,
Заинский район, 423507

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Төги авыл җирлегенең**
**башкарма комитеты**

Үзәк урамы, 8 нче йорт, Төги
авылы, Зәй районы, 423507

Телефон, факс 60-5-02. Электронный адрес: Turg.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**31.01.2025 г.**

**КАРАР**
**№ 89**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында 23.01.2025 № 33 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Уставына таянып,

## карар бирәм:

1. 2025 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9165,37 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2024 елның 30 гыйнварындагы 72 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй

муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Т.В. Попова**

Зәй муниципаль районы
Төги авыл җирлеге
башкарма комитетының
31.01.2025 ел
89 номерлы карарына
1 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән
Төги авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3486,04 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1490,01 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4189,32 |
| Барысы | 9165,37 |

Зәй муниципаль районы
Төги авыл җирлеге
башкарма комитетының
31.01.2025 ел
89 номерлы карарына
2 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән
Төги авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 955,88 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2601,58 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1454,39 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4153,52 |
| Барысы | 9165,37 |